**«ПЕЧӘН БАЗАРЫ»**

**Пресс-релиз**

**Игътибар үзәгендә – татар йорты интерьеры**

26-29 август көннәрендә Иске Татар бистәсендә (Кабан күле яр буенда) татар дизайны дөньясының төп вакыйгасы – **«Печән базары»** татар шәһәр мәдәнияте һәм дизайны фестивале узачак. Ел саен уздырылучы әлеге мәдәни-иҗади чара быел тагын да киңрәк форматта, тирәнрәк эчтәлек белән тәкъдим ителәчәк.

«Печән базары» Бөтендөнья татар яшьләре форумы кысаларында үткәрелә һәм елдан-ел татар мәдәниятенә битараф булмаган меңләгән кешене бер мәйданга җыя. Быел ул **4 көн** дәвам итәчәк һәм милли рух, заманча иҗат, шәһәр мәдәнияте, гореф-гадәтләр һәм яшәеш фәлсәфәсе белән сугарылган кабатланмас мохит тудырачак.

2013 елдан бирле үткәрелә торган фестиваль быел 13нче тапкыр уза һәм татар йорты темасына багышлана. Татар халкы өчен йорт – ул гади генә яшәү урыны түгел, ә үзенә күрә бер дөнья: хәтер, тәрбия, осталык, матурлык, ягымлылык тупланган мохит. Шуңа күрә йорт эчендәге бизәлеш, көнкүреш әйберләре, милли элементлар быелгы фестивальдә үзәк урынны били.

Быелгы фестивальнең максаты – заманча дизайнерлар иҗат иткән әйберләр ярдәмендә фатир яки йорт интерьерын татар стилендә бизәп булуын күрсәтү. 2023 елда «Печән базары» фестивалендә Fashion Tatar мода күрсәтүе оештырылды, аның бурычы – «Печән базары» дизайн-маркетында тәкъдим ителгән әйберләр белән заманча татар образы тудырып булуын ассызыклау иде. Быел исә без заманча дизайнерларның эшләнмәләре ярдәмендә татар стилендә интерьер булдырырга һәм йортны милли рухта җиһазландырырга мөмкин икәнен дәлилләргә ниятлибез.

**Фестиваль программасында**: дизайн-маркет, балалар һәм олылар өчен остаханәләр, лекторий, фотоаланнар, чәй эчү йоласы, кино, заманча татар музыкасы, «СалаваTik» балалар төркеме концерты һ.б. чаралар каралган.

Биредә Казаннан һәм Россиянең төрле төбәкләреннән килгән дизайнерлар, кул эшләре осталары, милли рухтагы әйберләр җитештерүчеләр үз продукциясен тәкъдим итәчәк. Балалар өчен махсус иҗади остаханәләр, уйнау, өйрәнү, күңел ачу мәйданчыклары оештырыла. Фестиваль вакытында балалар өчен шулай ук «СалаваTik» балалар төркеменең концерт программасы оештырылачак. Моннан тыш, театр сәнгатен сөючеләрне иммерсив спектакльләр көтә, ә белемгә һәм фикер алышуга тартылучылар

«Ачык университет» лекториясендә катнаша ала. Шул ук вакытта шәһәр кунаклары өчен Кабан буе буйлап аудио-променадлар, тематик экскурсияләр планлаштырыла.

Кичке якта «Печән базары» мәйданында заманча татар музыкасы, этно-джаз, балалар өчен концертлар һәм халыкчан чыгышлардан торган бай музыкаль программа тәкъдим ителәчәк: сәхнәдә яшьләр яратып өлгергән «Yummy Music», «СалаваTik» төркеме һәм Айдар Ниязов җитәкчелегендәге оркестр чыгыш ясаячак.

Фестиваль барышында тематик фотоаланда истәлеккә фотосурәтләр ясарга һәм үләннәр белән чәй әзерләү осталыгына өйрәнергә мөмкин булачак – монда татар чәй эчү йоласы буенча остаханәләр узачак. Моннан тыш, быел беренче тапкыр «Татар винтаж» – милли стильдәге винтаж әйберләр сату-алмашу мәйданчыгы оештырылачак.

Быелгы фестивальнең төп темасы – татар йорты интерьеры. Шуңа бәйле рәвештә, лекцияләрдә татар халкының яшәеше, интерьерга салынган мәгънә, бизәлештә традицияләр белән заманча элементларның бәйләнеше, гомумән, татар халкының көнкүреше турында белеп булачак. Спикерлар арасында сәнгать белгечләре һәм тарихчылар гына түгел, ә архитектура осталары һәм интерьер дизайнерлары, шул исәптән Русиянең башка төбәкләреннән килгән белгечләр дә чыгыш ясаячак.

Фестивальдә татар дизайнерлары, рәссамнар, кулинарлар, музыкантлар һәм башка иҗади индустрия вәкилләренең эшләрен күрергә мөмкин. Быелгы фестивальдә бөтен дөньядан меңгә якын татар җыелачак «Милләт җыены» делегатларының да катнашуы көтелә.

***Программа:***

**<u>26 август</u>**

- **12:00-21:00** – «Печән базары» маркеты
- **12:00-21:00** – Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты күргәзмәсе
- **12:00-21:00** – «Татар винтаж» гараж сату ярминкәсе
- **12:00-20:00** – Балалар зонасында остаханәләр
  **12:00-21:00** – Чәйханә зонасы
- **16:00-19:00** – Иммерсив спектакль
- **17:30** – ГАПИТ «Печән базары» (Милләт җыены делегатлары белән очрашу)
- **17:30-19:00** – Милләт җыены делегатларының Печән базарына килүе

- **17:30-19:00** – Бөтендөнья татар яшьләре форумы делегатларының Печән базарына килүе
- **17:00-19:30** – Ачык университет (лекторий)
- **19:30-20:30** – Айдар Ниязов оркестры концерты

---

**27 август**

- **12:00-21:00** – «Печән базары» маркеты
- **12:00-20:00** – Балалар зонасында остаханәләр
- **12:00-21:00** – Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты күргәзмәсе
- **12:00-21:00** – Чәйханә зонасы
- **18:00-21:00** – Концерт (Yummy Music)
- **20:00** – «Киносреда»: «Моң. Аңлатма» фильмы (Шиһабетдин Мәрҗани йорты ишегалдында)

---

**28 август**

- **12:00-21:00** – «Печән базары» маркеты
- **12:00-20:00** – Балалар зонасында остаханәләр
- **12:00-21:00** – Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты күргәзмәсе
- **12:00-21:00** – Чәйханә зонасы
- **16:00-18:00** – «Тристори» плейбэк театры
- **18:00-19:00** – Аудиогид презентациясе

---

**29 август**

- **12:00-21:00** – «Печән базары» маркеты
- **12:00-21:00** – Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты күргәзмәсе
- **12:00-21:00** – Чәйханә зонасы
- **12:00-20:00** – Балалар зонасында остаханәләр
- **12:00-15:00** – Ачык университет (лекторий)
- **13:00** – «Салаватики» концерты
- **18:00-21:00** – «Хәрәкәттә – бәрәкәт»

## ДИЗАЙН-МАРКЕТ

«Печән базары»ның йөрәге – дизайн-маркет. Быел ул татар йорты темасына багышлана. Шуңа күрә быелгы маркетта йорт эчендәге җиһазлар,

көнкүреш әйберләре, милли бизәкләр, интерьер детальләре, керамика, текстиль, кул эшләре үзәк урында булачак.

Татарстан районнары, Уфа, Пермь, Новосибирски, Төмән, Киров, Оренбур, Самар, Кәтринбур, Сочи, Түбән Новгород, Мәскәү һ.б. төбәкләрдән дизайнерлар катнашачак. Татарча заманлаштырылган киемнән тыш, биредә татар телендә өстәл уеннары, балалар өчен китаплар, танылган зәңгәр шәл, чигүле татар сөлгеләре, зәркән эшләнмәләре, сувенирлар, күннән һәм текстильдән эшләнгән әйберләр, Идел буе Болгарының төп һөнәрләренең берсе булган керамик әйберләр, шулай ук татар милли стилендә интерьер әйберләре сатып алырга мөмкин булачак.

«Печән базары» маркетында алынган һәр әйбер – ул кулдан эшләнгән сәнгать үрнәге генә түгел, ә татар рухын саклаган бер кыйммәт тә. Монда үзең өчен генә түгел, якыннарың өчен дә истәлеккә лаеклы бүләк табып була.

*Урыны: Кабан күле яр буе, Шиһабетдин Мәрҗани урамы*

*Вакыты: һәр көн 12:00-21:00 сәгатьтә*

## АЧЫК ҺАВАДА «АЧЫК УНИВЕРСИТЕТ»

«Ачык Университет» лекториясе Печән базары кысаларында ачык һавада узачак. Биредә татар мәдәнияте, сәнгате, архитектурасы, дизайны, тарихы кебек актуаль темаларга лекцияләр, дискуссияләр һәм презентацияләр көтелә. Чарада үз эшенең осталары, галимнәр, белгечләр катнаша.

**26 август көнне 17:00-19:30**

17:00 сәгатьтә – *«Татар йорты интерьерын бизәү үзенчәлекләре»*

Лектор: Солтанова Рауза Рифкать кызы – сәнгать фәннәре докторы, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының сәнгать белеме үзәге мөдире, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Баки Урманче исемендәге премия лауреаты.

18:00 сәгатьтә – *«Татарлыкны чагылдырган заманча интерьер җиһазлары. Актуальлек. Өйдә татар дизайнын ничек булдырырга?»*

Лектор: Җәмилә Хөснетдинова – архитектор, Miras Design студиясенә нигез салучы. Ул татар визуаль кодларын интерьерда куллану тәҗрибәсе белән уртаклашачак.

**<u>29 август 12:00-15:00</u>**

12:00-13:00 – *«Татар йорты интерьерын өйрәнү: тарихи күзәтү»*

Лектор: Абзалов Ленар Фиргать улы – Казан федераль университетының Татарстан тарихы кафедрасы доценты.

13:00-13:30 – *«Татар йортының традицион эчке бизәлеше һәм борынгы төрки чор интерьерлары арасындагы бәйләнеш»*

Лектор: Эндже Ильдаровна – (регалияләр өстәләчәк).

13:30-14:00 – *«Татарлыкны чагылдырган тию-мебель»*
Лектор: Мингалимова Эльвира Айрат кызы – интерьер дизайнеры.

14:00-15:00 – *Татар дизайны икътисады: татар дизайнерлары катнашында дискуссия*

Модераторлар: Гөлназ Бәдретдин, Рәдиф Кашапов.

Лектория ирекле форматта уза. Биредә һәркем үз фикерен җиткерә һәм яңа идеяләр белән бүлешә ала.

*Урын: Кабан күле яр буе (Камал театры ягыннан төшү)*

## «ТАТАР ВИНТАЖ» – МИЛЛИ СТИЛЬДӘГЕ ВИНТАЖ ӘЙБЕРЛӘР САТУ-АЛУ МӘЙДАНЧЫГЫ

26 август көнне МатурShik бренды белән берлектә татар винтаж әйберләренә багышланган махсус гараж-ярминкә оештырыла.

Винтаж элементлар бүгенге заман йортларына үзенчәлекле җылылык һәм милли төсмер өсти. Бу ярминкәдә татар стилен чагылдырган винтаж савыт-саба, вазалар, лампалар, пәрдәләр, эскәтерләр, келәмнәр һәм йорт өчен төрле матур әйберләр тәкъдим ителәчәк. Әгәр дә сездә татар рухын чагылдырган кием-салым, аксессуарлар яки башка елларда Печән Базарында алынган әйберләр бар икән, без аларны да кабул итәргә шат булырбыз!

Максатыбыз – татар винтаж мәдәнияте төшенчәсен формалаштыру, ягъни үткән заманның мода, дизайн һәм көнкүреш әйберләрен кабат куллану аша татар мирасына яңа сулыш өрү.

Винтаж яратучылар һәм татар көнкүрешенең тарихына кагылырга теләүчеләр өчен менә дигән мөмкинлек.

*Урыны: Кабан күле яр буе*

*Вакыты: 26 август 12:00-21:00 сәгатьтә*

## Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты күргәзмәсе

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты «Печән базары» фестивалендә үз мәйданчыгын тәкъдим итә. Күргәзмәдә Идел буе һәм Урал төбәгенең татар интерьеры белән танышырга мөмкин булачак. Әлеге мәйданчык көн саен 12:00дән 21:00гә кадәр эшли.

*Вакыты: һәр көнне 12:00-21:00 сәгатьтә*

## ТАТАРЛАРНЫҢ ЧӘЙ ЭЧҮ ЙОЛАСЫ

Татар чәйханәсе – фестивальнең җылы рухын тагын да ныграк тоярга мөмкинлек бирүче урын. Татар чәйханәсендә көн дәвамында татарның чәй эчү йоласы һәм этикеты буенча остаханәләр оештырылачак. Кабан күленә карап, татарлар өчен традицион үләннәр һәм киптерелгән җиләкләр белән хуш исле татар чәеннән авыз итеп булачак.

*Вакыты: һәр көнне 12:00-21:00 сәгатьтә*

*Урын: Шиһабетдин Мәрҗани урамы*

## БАЛАЛАР ЗОНАСЫ

Иң кечкенә кунаклар өчен махсус иҗади мәйданчык оештырылачак. Балалар мәйданында милли уеннар, кул эшләренә багышланган остаханәләр, рәсем ясау, татар орнаментларын өйрәнү, табигый материаллар белән эшләү, шулай ук театр элементлары белән баетылган күңелле программа оештырылачак. Биредә күңел ачу гына түгел, ә милли тәрбиягә дә басым ясала.

*Вакыты: һәр көнне 12:00-20:00 сәгатьтә*

## ИММЕРСИВ СПЕКТАКЛЬЛӘР

***КФУның «Мизгел» труппасы катнашында***

«Язгы Печән базары»нда күпләрнең күңелләренә хуш килгән иммерсив спектакль быел да тамашачыларны куандырачак. 26 август көнендә Кабан күле яр буе спектакль мәйданчыгына әйләнәчәк. Чыгышны Казан федераль университетының «Мизгел» театр труппасы тәкъдим итә.

*Вакыты: 26 август көнне 16:00-19:00 сәгатьтә*

***Плейбэк-театр форматындагы «Тристори» спектакле***

Плейбэк-театр форматындагы «Тристори» спектаклендә тамашачылар (залдан теләгән һәркем) үз тарихларын сөйли, ә актерлар шунда ук әлеге вакыйганы сәхнәдә уйнап күрсәтә.

«Аулак» плейбэк-перформанс – ул җанлы, җылы очрашу. Биредә сезнең тарихлар чын сәхнә әсәренә әверелә. Күз алдыгызга китерегез: пәрәмәч пешерүнең иң күңелле мизгелләре. Дәү әни йомшак камыр җәя, син кечкенә генә кашык белән ит саласың, апа белән әни түгәрәк пәрәмәчләр әвәли, ә мич янында туган апа аларны алтынсу төскә кергәнче кыздыра. Өйгә тәмле пәрәмәч исе тарала…

Ә плейбэк нәрсә соң ул? Бу – театр. Ләкин гадәти генә түгел, ә тамашачы тарихларын сәхнәләштергән театр. Биредә һәркем үзенең тормышыннан бер вакыйганы сөйли ала, ә сәхнәдәге артистлар шунда ук әлеге тарихны импровизация аша яңадан тудыра. Монда бернинди дә сценарий юк. Бу – җылы әңгәмә, хисләргә һәм хатирәләргә нигезләнгән сәнгать. Син төп автор.

*Вакыты: 28 август 16:00-18:00 сәгатьтә*

## ФОТОАЛАН

Фестиваль барышында берничә тематик фотоалан оештырылачак. Фестивальнең төп фотоаланы Мәрҗани урамындагы чәй аланында урнашачак. Фотозона татар кунак бүлмәсе стилендә эшләнәчәк: биредә заманча татар интерьер элементлары белән беррәттән сандык, борынгы комод кебек винтаж әйберләр дә урын алачак. Фотозонада кулланылган һәр нәрсәне «Печән Базары» фестивале маркетыннан сатып алырга мөмкин булачак. Фотозона бизәлеше белән архитектор һәм дизайнер Җамилә Хөснетдинова шөгыльләнә.

*12:00-21:00*

*Урыны: Шиһабетдин Мәрҗани урамы башы*

## МИЛЛИ МУЗЕЙ МӘЙДАНЧЫГЫ

Өченче ел рәттән «Печән базары» фестивалендә ТР Милли музее үз мәйданчыгын булдырачак. Биредә фестиваль кунакларын лекцияләр, Иске Татар бистәсе буйлап экскурсияләр, остаханәләр, балалар өчен уеннар һ.б. көтә. Монда ук Милли музей экспонатларына нигезләнгән эксклюзив сувенирлар һәм аксессуарлар сатып алырга һәм татар милли киемендә фотосессия ясарга мөмкин булачак.

*Урыны: Шиһабетдин Мәрҗани урамы башы*

## ОТТЫРЫШСЫЗ ЛОТЕРЕЯ

Быел «Печән базары» фестивале кысаларында лотерея оештырылачак! Фестивальдә Бөтендөнья татар яшьләре форумы эшчәнлегенә багышланган «Идел» яки «Ялкын» журналы номерын алучы һәркемне «Печән базары» маркетында катнашучы дизайнерлардан бүләкләр көтә.

*Вакыты: 29 август 12:00-20:00*

*Урыны: Шиһабетдин Мәрҗани урамы башы*

## КИНО

«Печән базары» фестиваленең кинопрограммасында быел бер документаль фильм тәкъдим ителәчәк.

27 август кичендә күрсәтеләчәк «Моң. Аңлатма» фильмы – татар халкы өчен бик таныш, әмма һәркем төрлечә аңлый торган «моң» төшенчәсенә багышланган. Фильмны журналист, музыкант Рәдиф Кашапов төшергән. Әсәрдә шагыйрьләр, музыкантлар, тарихчылар, сәнгать белгечләре аша «моң» төшенчәсенең төрле яклары ачыла: ул – хис, хәтер, тавыш, вакыт, хәтта каршылык. Фильм тамашачыны моң аша үз халкын яңача танырга этәрә.

Әлеге фильм тамашачыны милли мәдәниятебезнең тирән катламнарына алып керә һәм бүгенге татар дөньясын тагын да тулырак аңларга мөмкинлек бирә.

*Вакыты: 27 август 20:00 – «Моң. Аңлатма» фильмы;*

*Урын: Шиһабетдин Мәрҗани йорты ишегалды*

## МӘҮЛИД

29 августта Казанда Мөхәммәд Пәйгамбәрнең ﷺ туыына багышланган шәһәркүләм Мәүлид бәйрәме узачак. Быел тантана бөек юбилей – һиҗри буенча Аллаһ Илчесенең 1500 ﷺ еллыгы белән истәлекле. Шуңа күрә Диния нәзарәте беренче тапкыр республика җитәкчелеге, ТР Мәдәният министрлыгы һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының «Иске шәһәр» Префектурасы ярдәмендә аны аеруча зур итеп һәм Республика Көне чаралары кысаларында оештыра. Бәйрәмгә теләгән һәркем: казанлылар һәм башкала кунаклары чакырыла.

Шәһәркүләм Мәүлид Казанда Иске Татар бистәсендә татар дин галиме Ш.Мәрҗани һәйкәле янында узачак. Бәйрәм 15:00 сәгатьтә башлана.

Мәүлидне оештыручылар төрле яшьтәге кунаклар өчен бай дини-мәгърифәтчелек программасы әзерләде. Мәүлиднең иң онытылмас мизгеле булып хаҗга юлламалар уйнату торачак. Анда Мәүлидкә килгән һәр мөселман катнаша ала. Фестивальнең махсус кунаклары – Россиядә иң танылган нәшид башкаручы "Нәшидүл ислам" төркеме җырчылары. Алар үзләренең иң популяр нәшидләрен – сөекле Рәсүлебез ﷺ һәм Аллаһы Тәгаләгә мәхәббәт турында җырларын тәкъдим итәчәк. Нәшидләр гарәп һәм рус телләрендә яңгыраячак. Шулай ук бәйрәм сәхнәсендә Мәүлид турында театральләштерелгән тамаша күрсәтеләчәк, халык яраткан хәзрәтләр вәгазьләр сөйләячәк, ә танылган татар артистлары һәм коллективлары дини кануннар кысаларында үзләренең иҗади номерлары белән чыгыш ясаячак. Балалар өчен викториналар узачак: аларга бүләкләр биреләчәк.

## ХӘРӘКӘТТӘ – БӘРӘКӘТ

29 август көнне кичке сәгать алтыда Кабан күле яр буенда «Хәрәкәттә – бәрәкәт» проектының 5 еллыгы уңаеннан оештырылган БИЮ КӨРӘШЕ конкурсының финалы узачак. Шарт буенча бәйгедә профессиональ булмаган биючеләр, ягъни татарча оста биюче гади халык катнаша. Финалга узганнар исә берничә турдан торган сынауларда үзара ярышачак. Иң шәп биючене билгеләү өчен жюри әгъзалары чакырыла. Җиңүчене шәп бүләк – 300 000 сум акча көтә!

Кызу финалны Замирә Рәҗәпова һәм Татарстанның халык артисты Җәвит Шакиров алып барачак. Җырлы-музыкаль номерлар белән үрелеп барачак бию батлын тамаша кылырга рәхим итегез!

Искәртеп узыйк, Казан Мэриясенең «Хәрәкәттә – бәрәкәт» проекты 2021 елдан башлап Парклар һәм скверлар дирекциясе белән берлектә ТР Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме белән оештырылып килә. Төп максат – татар халык биюләре аркылы туган телне саклау. Шуңа күрә «Хәрәкәттә – бәрәкәт»нең барлык чаралары да татар телендә алып барыла. Соңгы елларда проектның төгәл урыны һәм вакыты билгеләнде: татар биюен яратучылар җәй дәвамында һәр пәнҗешәмбе кичке сәгать алтыда Кабан күле яр буенда очраша.

БИЮ КӨРӘШЕнең финалы исә 29 август, җомга, 18.00да «Печән базары» фестивале кысаларында узачак.

## КИЧКЕ ЧАРАЛАР (КОНЦЕРТ)

**26 август** киче – «Печән базары»ның беренче көне дирижер, композитор Айдар Ниязов җитәкчелегендәге оркестр чыгышы белән тәмамланачак. 19:30-20:30 сәгатьләрдә узачак бу концертта милли рухтагы инструменталь әсәрләр яңгыраячак.

**27 август** көнне 18:00дән 21:00гә кадәр, фестиваль мәйданында Yummy Music лейблы ярдәмендә оештырылган концерт булачак. Заманча татар музыкасы, тере тавыш, халык арасында популяр җырлар – бу кичне җанлы музыкаль бәйрәмгә әйләндерәчәк.

**29 август** көнне 13:00 сәгатьтә балалар өчен «Салаватиклар» концерты тәкъдим ителә. Җырлар, биюләр, интерактив уеннар белән баетылган бу тамаша нәниләр өчен генә түгел, әти-әниләр өчен дә шатлыклы мизгелгә әверелер.

**29 август** 18:00-21:00 аралагында «Хәрәкәттә – бәрәкәт» оештырыла. Теләгән һәркем татар халык биюләренең иң гади хәрәкәтләрен өйрәнеп, музыка астында хәрәкәтләнеп ала алачак.

«Печән базары»ның соңгы көнендә Казанда һәм Татарстанның төрле шәһәрләрендә иҗат итүче талантлы татар артистларының да чыгышлары көтелә. Алар төрле стильләрдә эшли: фолк, поп, этно, электро, әмма максатлары бер: татар телен һәм мәдәниятен бар дөньяга яңгырату.

*Урыны: Кабан күле яр буе*

**Фестивальнең барлык чаралары да татар телендә уза. Керү ирекле**

«Печән базары»ның оештыручысы – Бөтендөнья татар яшьләре форумы.

Фестивальнең партнерлары: ТР Мәдәният министрлыгы, Бөтендөнья татар конгрессы, Казан шәһәре Башкарма комитеты, Казанның Парклар һәм скверлар дирекциясе, «Иске шәһәр» префектурасы һәм «Тарихи мохит» муниципаль бюджет учреждениесе, «Салават күпере», «Сабантуй» һәм «Салават күпере» журналлары, Yummy Music, ТР Милли музее, ШАХ GROUP Баклава.

«Печән базары» фестивале беренче тапкыр 2013 елның апрелендә татар шагыйре Габдулла Тукайның вафатына 100 ел тулуга багышланган иде. Фестивальнең максаты – XX гасыр башы, ягъни Тукай яшәгән һәм иҗат иткән чор атмосферасын торгызу була. Моның өчен Нурулла мәчете янында урам ярминкәсе оештырыла. Ярминкәдә катнашучылар өчен дресс-код кертелә – киемдә ул чордагы шәһәр халкының татар милли киеме элементлары булырга тиеш була. Бу урын очраклы гына сайланмаган – Печән базары төрле товарлар сату урыны гына түгел, ә Казан татарларының очрашу һәм бер-берсе белән аралашу, яңалыклар белән танышу һәм аралашу урыны да булган, ягъни Печән базары Казан татарларының мәдәни һәм иҗтимагый тормыш үзәге булган. Ярминкәдә катнашучыларның барысына да дресс-код кертелде – киемнәрдә ул чор шәһәр халкының татар милли киемнәре элементлары булырга тиеш.

---

*Хөрмәтле матбугат вәкилләре!*

*Аккредитация өчен сездән корреспондентның ФИО, матбугат чарасының исемен, телефон һәм электрон почта адресын* ***pechan.bazar@mail.ru*** *адресына җибәрүегезне сорыйбыз.*

*Барлык сораулар буенча, шулай ук фестивальнең оештыручылары һәм катнашучылары белән интервьюлар оештыру өчен:*

***Гөлназ Бәдретдин +7 927 430-68-82***

***Айзилә Абдрахманова +7919 642-14-34***

*Хөрмәт белән,*

***Бөтендөнья татар яшьләре форумының матбугат хезмәте***

*Безнең социаль челтәрләр:*

**https://vk.com/pechenbazar**

**https://t.me/tatardesign_official**